ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.02.2019 г. Заинск № 61

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 июлендәге 1202 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында, пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында " карарына үзгәрешләр кертү турында»**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 статьясы, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 23 июлендәге 1202 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажирлар йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына 1 нче кушымтаның 5 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

   «5.1. Муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы йөртүчедән төшеп калучы керемнәрне каплауга субсидияләр күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча хисап юлы белән билгеләнә:

С = З – Д

монда:

С - субсидия күләме, мең сум;

З – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 11 июнендәге 454 номерлы карары белән расланган транспорт чарасы классыннан (38 сум 27 тиен) һәм маршрутның озынлыгыннан чыгып, автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга тотылган чыгымнар (1 километр өчен 38 сум 27 тиен) һәм маршрутның озынлыгы;

Д - җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар ташуның муниципаль маршрутлары буенча йөргән өчен түләүдән алынган керемнәр мең сум тәшкил итә.

Ташучының кереме составында түбәндәге керем төрләре исәпкә алына:

- муниципаль ташу вакытында пассажирлар йөртүгә һәм багаж алып баруга бер тапкыр билетлар сатудан кергән табыш;

- социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның ташламалы категорияләрен йөртүгә бәйле барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан бирелә торган транспорт йөртүченең чыгымнарын компенсацияләү суммасы.

Шул ук вакытта пассажирлар ташучының Кереме транспорт чарасын 40% тан да ким булмаган тутыру күрсәткеченнән чыгып исәпләнә.

2. 2 нче кушымтада Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә шәһәр яны элемтәсенең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны җайга салынулы тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар һәм багаж йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының лицевой счетыннан төшеп калган керемнәрне каплауга акчаларны, субсидия алу хокукын раслаучы документлар каралуга бирелгән көннән соң, 10 (эш) эш көне эчендә ташучы счетына күчерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://zainsk.tatarstan.ru/.

5. 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н.А. Нифатовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

М.М. Хабибуллин
885558 3-13-37